# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге составына керүче Кыраул торак пунктында 2023елга үзара салым кертү турында

№ 3 17 октябрь 2022 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчыстатьялары, «Татарстан Республикасындаҗирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясынигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Кыраул торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Кыраул торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белеем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2023 елда 500(биш йөз ) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

-Кыраул торак пунктында зират рәшәткәләрен алыштыру(сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү);

- Кыраул торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;
- Кыраул торак пунктында урамнарны яктырту объектларын карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (махсус җиһазлар, лампалар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).

3.Әлеге карарны Олыяз авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнарҗыенындарәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе И.Я.Хаев